ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында”**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 44 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 11 – 13 пунктлар өстәргә:
“11) плотиналарны, суташлагыч, сутөшергеч һәм сучыгаргыч корылмаларны кертеп, су мохите йогынтысына дучар итеклә торган, су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранганнарының, зарарлы йогынтысын булдырмау өчен билгеләнгән корылмаларга; насос станцияләренә; суднолар узу шлюзларына; суднокүтәргечләргә; су басулардан, елгалар һәм сусаклагыч ярларын, елгаларның ярларын һәм үзәннәре төбен ишелүдән саклау өчен билгеләнгән корылмаларга; чикләү корылмаларына; дамбаларга, ярларны ныгыту корылмаларына, яр буйларына, шулай ук анда урнашкан төзекләндерү һәм коммерциячел инфраструктура объектларына; пирсларга; техник су белән тәэмин итү системалары корылмаларына карата “Концессия килешүләре турында” 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән шартнамәләргә, килешүләргә таянып гидротехник корылмалар булдыруны, төзүне, эксплуатацияләүне, реконструкцияләүне, модернизацияләүне гамәлгә ашыручы оешмалар;
12) Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{6}$ статьясындагы 2 пунктының

3 пунктчасы нигезендә бирелгән һәм Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының 25 пунктчасы яисә “Концессия килешүләре турында” 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре белән чиктәш чиге булган җир кишәрлекләрендә төзелгән мөлкәткә карата оешмалар;

13) плотиналарны, суташлагыч, сутөшергеч һәм сучыгаргыч корылмаларны кертеп, су мохите йогынтысына дучар ителә торган, су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранганнарының, зарарлы йогынтысын булдырмау өчен билгеләнгән корылмаларга; насос станцияләренә; суднолар узу шлюзларына; суднокүтәргечләргә; су басулардан, елгалар һәм сусаклагыч ярларын, елгаларның ярларын һәм үзәннәре төбен ишелүдән саклау өчен билгеләнгән корылмаларга; чикләү корылмаларына; дамбаларга, ярларны ныгыту корылмаларына, яр буйларына, шулай ук анда урнашкан төзекләндерү һәм коммерциячел инфраструктура объектларына; пирсларга; техник су белән тәэмин итү системалары корылмаларына карата Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының 25 пунктчасы нигезендә аренда шартнамәләренә таянып бирелгән җир кишәрлекләрендә 2017 елның 1 гыйнварыннан соң булдырыла торган гидротехник корылмаларны төзүне һәм аннан соңгы эксплуатацияләүне үз һәм (яисә) заем акчалары исәбеннән гамәлгә ашыручы оешмалар.”;

б) $2^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$2^1$. 0,5 процент күләмендәге салым ставкасы түбәндәгеләр мөлкәтенә билгеләнә:

1) йөк автотранспорты чаралары җитештерүчеләр;

2) плотиналарны, суташлагыч, сутөшергеч һәм сучыгаргыч корылмаларны кертеп, су мохите йогынтысына дучар ителә торган, су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранганнарының, зарарлы йогынтысын булдырмау өчен билгеләнгән корылмаларга; насос станцияләренә; суднолар узу шлюзларына; суднокүтәргечләргә; су басулардан, елгалар һәм сусаклагыч ярларын, елгаларның ярларын һәм үзәннәре төбен ишелүдән саклау өчен билгеләнгән корылмаларга; чикләү корылмаларына; дамбаларга, ярларны ныгыту корылмаларына, яр буйларына, шулай ук анда урнашкан төзекләндерү һәм коммерциячел инфраструктура объектларына; пирсларга; техник су белән тәэмин итү системалары корылмаларына карата “Концессия килешүләре турында” 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән шартнамәләргә, килешүләргә таянып, гидротехник корылмалар булдыруны, төзүне, аларны эксплуатацияләүне, реконструкцияләүне, модернизацияләүне гамәлгә ашыручы оешмалар;

3) Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының 3 пунктчасы нигезендә бирелгән һәм Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 пунктының 25 пунктчасы яисә “Концессия килешүләре турында” 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре белән чиктәш чиге булган җир кишәрлекләрендә төзелгән мөлкәткә карата оешмалар;

4) плотиналарны, суташлагыч, сутөшергеч һәм сучыгаргыч корылмаларны кертеп, су мохите йогынтысына дучар ителә торган, су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранганнарының, зарарлы йогынтысын булдырмау өчен билгеләнгән корылмаларга; насос станцияләренә; суднолар узу шлюзларына; судноҗтәргечләргә; су басулардан, елгалар һәм сусаклагыч ярларын, елгаларның ярларын һәм үзәннәре төбен ишелүдән саклау өчен билгеләнгән корылмаларга; чикләү корылмаларына; дамбаларга, ярларны ныгыту корылмаларына, яр буйларына, шулай ук анда урнашкан төзекләндерү һәм коммерциячел инфраструктура объектларына; пирсларга; техник су белән тәэмин итү системалары корылмаларына карата Россия Федерациясе Җир кодексының 39$^6$ статьясындагы 2 пунктының 25 пунктчасы нигезендә аренда шартнамәләренә таянып бирелгән җир кишәрлекләрендә 2017 елның 1 гыйнварыннан соң булдырыла торган гидротехник корылмаларны төзүне һәм аннан соңгы эксплуатацияләүне үз һәм (яисә) заем акчалары исәбеннән гамәлгә ашыручы оешмалар.”;

2) 5 статьяга 8 пункт өстәргә:

“8) 2022 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 11 – 13 пунктларын.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, аның 1 статьясындагы 1 пунктының “б” пунктчасыннан тыш, 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының “б” пунктчасы 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 ел, 26 декабрь
№ 102-ТРЗ